КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1261

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2008 - 2010 елларга “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләрен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2008 - 2010 елларга “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасыа һәм әлеге карар белән расланган 2008 - 2010 елларга “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләрен үзгәрешләр кертү хакында” 2007 елның 20 июлендәге 315 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2008 ел, 10 сентябрь, 655 нче карарының 1 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 10 сентябрь, 655 нче карары белән расланган «2008-2010 елларга “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында торак сатып алу өчен яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 15 июнь, 391 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 10 сентябрь, 655 нче карары белән расланган «2008 – 2010 елларга «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында" 2009 ел, 31 август, 596 нчы карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин